



- Шагыйрь
- Журналист
- Татарстан Дәүләт Советы депутаты
- Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча комиссия рәисе

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин 1948 елның 1 августында Башкортстан Республикасының Илеш районы Нәҗеде авылында дөньяга килгән.

***Р.Миңнуллин - гаилә җанлы кеше.***

Р.Миңнуллин – тормышта гади татар кешесе. Ул - сабыр, ипле, кешелекле, миһербанлы, гаилә җанлы шәхес. Хатыны Клара белән алар ике бала үстереп аякка бастырганнар. Балалары- Алмаз, Таңсылу әти-әнисенең йөзенә кызыллык китермиләр. Р.Миңнуллин – яхшы ир дә, кайгыртучан ата да, сөекле бабай да.





# ХАТЫНЫ КЛАРА БЕЛӘН.

Балалары Алмаз һәм Таңсылу белән.

# РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН – ЛИРИК ШАГЫЙРЬ.

КӨТМӘГЕЗ МИННӘН ФӘЛСӘФӘ,
МИН ГАДИ БЕР ЛИРИК.
ЛИРИКЛАРГА НИШЛӘСӘ ДӘ,
НИ ЯЗСА ДА ИРЕК.

ХИСЛӘР БЕЛӘН ЭШ ИТӘМ МИН:
ҖАН, МОҢ, СӨЮ, САГЫШ...
АНДЫЙ ХИСЛӘР ҺӘР КЕШЕГӘ
КҮПТӘН ИНДЕ ТАНЫШ.

# *Әрнүле балачак хатирәләре.*


**Әрнүле балачак ул – сирәк язмышларның берсе, бу – ятимлек әчесе. Роберт – әтисез үскән малай.**

**Син юкка да күптән,**
**Гомер үткән.**
**Үзем хәзер әти булырлык.**
**Әнкәй генә елаштыра менә...**
**Тулырлык шул, күңел тулырлык**



Роберт Миңнуллин әнисе Гөлҗәүһәр апа белән

# Р.Миңнуллин – нәниләр шагыйре.



























# Туган илем, газиз җирем!

**Кошлардагы туган җирне сөю**
**Һәм сагыну миңа, аһ, таныш.**
**Мин Сөн кошы! Ике канатымның**
**Берсе – Илеш, берсе – Актаныш!**

**И Актаныш! Күпме җырларымны**
**Талларыңа куныр сайрадым.**
**Туган җирне сайлап алмыйлар да,**
**Сине менә үзем сайладым.**

Р.Миңнуллин


# Китап – күңел көзгесе


















# *Шигырьләрем җырлап тора*

Роберт Миңнуллин – югары зәвыклы, сизгер рухлы, дөньяны һәм кешеләрне үзенчә тасвирларга омтылучы лирик шагыйрь. Аның ике йөздән артык шигыре көйгә салынган.

# *Әнкәйләрнең бөеклеген соңрак... соңрак аңлыйбыз*

Әнкәй дә картайган инде,
Чәчләре дә агарган:
Нур сибелә, нур чәчелә,
Нур бөркелә алардан.
Бик килешә аклары да,
Сагынам карасын да.
Мин агарткан чәч тә бардыр
Ул чәчләр арасында.

# ДӘРӘҖӘЛЕ ИСЕМНӘРЕ

- Муса Җәлил исемендәге премия иясе
- Абдулла Алиш исемендәге премия иясе
- 

“Дөньядагы иң зур алма” исемле китабы өчен Г.Х.Андерсен исемендәге Почетлы диплом белән бүләкләнде.
- “Күчтәнәч” исемле балалар китабы өчен Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге бирелде.

Кешеләргә без яхшылык эшлик!

Эшләмәсәк – гарьлек.

Тик яхшылык эшләү җиңел түгел,

Ул – зур фидакарьлек!

Р.Миңнуллин